**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru 423115, Ульяновка авылы, Үзәк урам, 44 йорт

**29 ноябрь 2018 ел** **№ 96**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Ульяновка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2015 елның 14 октябрендәге 6 номерлы “Физик затлар мөлкәтенә салым турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 3 августында кабул ителгән 334-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым Кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 399 ст. 2 п. нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2015 елның 14 октябрендәге 6 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы карарына (2018 елның 13 июлендәге 82 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- 2 пунктның 2 пунктындагы 1 абзацында «фатирлар» сүзеннән соң «фатирларның бер өлеше» сүзләрен өстәргә:;

2 пунктның 3 пунктындагы 1 абзацында «торак йортлар» сүзеннән соң «торак йортларның бер өлеше» сүзләрен өстәргә.

- 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә::

- "18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрне салым түләүдән азат итеп, ташлама бирергә".

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге рәисе,
Совет Башлыгы Шәмсетдинов С.З.